КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 октябрь г.Казань № 1225

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 158 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 158 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 11 июль, 566 нчы; 2019 ел, 24 сентябрь, 875 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 924 нче; 2019 ел, 8 ноябрь, 1024 нче; 2020 ел, 22 сентябрь, 857 нче; 2020 ел, 13 ноябрь, 1023 нче; 2021 ел, 24 май, 361 нче; 2021 ел, 6 август, 685 нче; 2021 ел, 11 октябрь, 968 нче; 2021 ел, 17 ноябрь, 1091 нче; 2022 ел, 4 февраль, 86 нчы; 2022 ел, 12 май, 433 нче; 2022 ел, 5 ноябрь, 1176 нчы; 2023 ел, 22 март, 323 нче; 2023 ел, 13 июль, 830 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – дәүләт программасы) расларга.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгын дәүләт программасының җаваплы башкаручысы итеп билгеләргә.»;

3 пунктта «чираттагы финанс елына» сүзләрен «чираттагы финанс елына һәм план чорына» сүзләренә алмаштырырга, «Программа» сүзен «дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карарга теркәлгән исемлек нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары үз көчен югалткан дип танырга.

3.Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин